Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«14» январь 2019 ел №01

Әлмәт шәһәре территориясендә мөстәкыйль
билгеләнгән, законсыз урнаштырылган
күчемсез милек объектларын
демонтажлау һәм күчереп утырту
чыгымнарын компенсацияләү

Әлмәт шәһәре территориясендә күчемсез милек объектларын урнаштыруны тәртипкә салу максатларында һәм Әлмәт шәһәре Советының «Әлмәт шәһәре территориясендә мөстәкыйль билгеләнгән, һәм (яки) законсыз урнаштырылган күчемсез милек объектларын ачыклау һәм сүтү тәртибе турында» 2017 елның 5 маендагы 79 номерлы карары, Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 1 августындагы 44 номерлы «Әлмәт шәһәре территориясендә мөстәкыйль билгеләнгән һәм законсыз урнаштырылган күчемсез милек объектларын демонтажлау һәм күчерү һәм чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында»гы карары (Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 28 августындагы 52 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре территориясендә мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган, демонтажлау һәм күчереп утыртырга тиешле күчемсез милек объектларын исемлеген расларга( 1 нче кушымта)

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» муниципаль автоном учреждениесенә (З.А. Сөләйманов) кушымта нигезендә «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә үз белдеге белән билгеләнгән һәм (яки) законсыз урнаштырылган күчемсез милек объектын сүтүне тәэмин итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 14 январе 01 номерлы карары белән расланган 1 нче кушымта

# Әлмәт шәһәре территориясендә мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган, демонтажлау һәм күчереп утыртырга тиешле күчемсез милек объектлары исемлеге

| № п/п | Мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган объектның урнашу урыны | Мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган объектның төре | Мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган объектның милек хуҗасы | Мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган күчемсез милек объектын демонтажлау һәм күчереп утырту вакыты | Мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган күчемсез милек объектының төгәл урнашу урыны | Мөстәкыйль билгеләнгән, законсыз урнаштырылган күчемсез милек объектын демонтажлау һәм күчереп утырту өчен җаваплы оешма, ФИО |
|---|---|---|---|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Әнвәр Баһаветдинов урамы, шәхси йортлар янында | шлагбаум | билгесез | 2019 елның 23 январенә кадәр | “Шәһәр автомобиль юллары идарәсе " муниципаль унитар предприятиесе | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» муниципаль автоном учреждениес |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш
буенча урынбасары — А.А. Мухаметзянов